**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**КЛЯШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КЕЛӘШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

422377 Тетюшский район, с.Кляшево, ул.Ленина, 12А

422377 Тәтеш районы, Келәш авылы,Ленин ур, 12А

тел. (84373) 5-60-39, факс 5-60-39, e-mail: Kls.Tet@tatar.ru
ОГРН 1021606559150, ИНН/КПП 1638001617/163801001

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**26 август, 2020 ел** **№ 1**

## Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлегенең Тоншерма торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын куллану сораулары буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль законының 56, 25.1 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарәләр турында” Татарстан Республикасы законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы “Келәш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 23 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 08 сентябрендә 14 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлегенең Тоншерма торак пунктында урнашкан Тоншерма авылы мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым чараларын куллану мәсьәләсе буенча халык җыены үткәрергә.

2. Халык җыенында тәкъдим ителүче сорауны раслау:

“Сез, 2020 елга җыелган 343675 (өч йөз кырык өч мең алты йөз җитмеш биш) сум күләмендәге гражданнарның үзара салым акчаларын “Тоншерма авылының зират территориясен койма белән әйләндереп алу”дан “инвентарьлар саклау өчен 135000 (йөз утыз биш мең)сум суммасына хуҗалык корылмасы сатып алу ”һәм “Тоншерма авылы эчендәге К.Маркс урамында урнашкан юлларны 208675 (ике йөз сигез мең алты йөз җитмеш биш) сум суммасына ремонтлау”га күчерергә ризамы?”

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрү йөкләнелә.

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы”нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырып халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар басылган көненнән башлап үз көченә керә.

**Ф.Х. Галимов**